Раслыйм: ____________

Мәктәп директоры:

# Фән белән кызыксынучы сәләтле балалар белән эшләү планы

Укытучы: Фадеева Нина Валентиновна

# Фән белән кызыксынучы сәләтле балалар белән эшләү планы

Укытучы:  Фадеева Нина Валентиновна

# Фән белән кызыксынучы укучылар исемлеге.

| № п/п | Укучының фамилиясе, исеме | Классы |
|---|---|---|
| 1. | Ермолаева Оксана | 5 |
| 2. | Фадеев Иван | 11 |
| 3. | Дмитриев Виталий | 7 |
| 4. | Морозова Марина | 5 |
| 5. | Дементьева Анастасия | 8 |
| 6. | Ермолаева Мария | 6 |
| 7. | Максимова Екатерина | 9 |

# Укучылар белән эшләү расписаниесе

| Көне | Вакыты | Класслар |
|---|---|---|
| Дүшәмбе | 13.10– 13.55<br>14.00-14.45 | 5-11 |
| Сишәмбе | 13.10– 13.55<br>14.00-14.45 | 5-11 |
| Чәршәмбе | 13.10– 13.55<br>14.00-14.45 | 5-11 |

# Сәләтле балалар белән эшләү максаты:

1. Сәләтле балалар белән эшне оештыруның яңа формаларын өйрәнү һәм кулланышка кертү, комплекслы системасын булдыру.
2. Сәләтле балалар белән эшнең авторлык педагогик технологияләрен тудыру.
3. Сәләтле балалар белән эшләүдә компетентлык дәрәҗәсен арттыру.
4. Авыр үзләштерүче балаларда фәнне өйрәнүгә кызыксыну (мотив)тәрбияләнүнең яңа технологияләрен тудыру, эш системасы булдыру. Укучыларга укытуның барлык баскычларында да дәүләт стандартларына туры килерлек белемнәр бирү

5. Сәләтле укучылар белән эшләү өчен, махсус биремнәр, анкета сораулары, олимпиада һәм конкурсларга әзерлек өчен, программалар төзү.
6. Укучыларның мәктәп, район һәм республика күләмендәге конкурсларда, олимпиадаларда катнашуы буенча отчетлар төзү.
7. Укучыларның район, республика чараларда катнашуын арттыру, аеруча призлы урыннар алуга, дәрестә һәм дәрестән соң даими эш алып баруга кызыксынуларын үстерү.
8. Олимпиадалар үткәрү турында положениеләрдә мәктәп, район, республика олимпиадаларының үткәрелү шартлары белән даими таныштыру;
9. Югары әхлакый сыйфатларга, интерактив, коммуникатив мөмкинлекләргә ия булган иҗади шәхес тәрбияләү.
10. Регионның, илнең реаль таләпләреннән чыгып, шәхеснең үзенең эчке мөмкинлекләрен уяту, конкурентлыкка сәләтле шәхес тәрбияләү.

# Аңлатма язуы

Укытуның төрле этабында укытучының психологик күзәтүләр алып баруы һәм укучылардагы үзгәрешне өйрәнеп торуы сорала; дәрестә кулланылган метод һәм алымнар укучыларның сәләтләре үсүенә ни дәрәҗәдә тәэсир итә, укучы күпме мөстәкыйль эшли ала, дәрестә катнашу дәрәҗәсе ничек, фән белән кызыксынуы үсәме, хәтер һәм дикъкать дәрәҗәсе, ихтыяры, фикерләү дәрәҗәсе ничек, аның актив яки пассив булуы, анализлый һәм йомгаклый белү сәләте, эш темпы ничек, ни өчен теге яки бу укучы материални аңламый яки биремнәрне эшләргә өлгерми һәм башка шундый мәсьәләләр белән укытучы кызыксынып торырга тиеш.

Дәрес материалы, кулланылган метод һәм алымнар, күнегүләр укучыларның яшь һәм белем аермалыкларын, гомуми үсеш дәрәҗәсен, психологик үзенчәлекләрен истә тотып сайлана.

Укучыларга белем һәм тәрбия бирү процессында укытучының уку эшен активлаштыруы , барлык укучыларның интеллектуаль, иҗади көчләрен, сәләтләрен белем алуга туплавы, аларның үзенә генә хас үзенчәлекләрен (психикасы, кызыксынуы, ихтыяҗы, омтылышы, сәләте, белем үзләштерү дәрәҗәсе, фикерләү дәрәҗәсе, хәтере, ихтыяр көче, сизгерлеге, эмоциональлеге), уңай һәм кимчелекле якларны, аларның белем дәрәҗәләрен даими өйрәнүе таләп ителә. Шул вакытта гына ул укучыларга дифференциаль һәм аерым (индивидуаль) якын киленә һәм кимчелекләрен булдырмау чараларын күрелә.

# Фəн белəн кызыусынучы укучылар белəн эшлəү планы.

| № п/п | Эшлəнəчəк эш төре | Чыганак |
|---|---|---|
| 1 | Фəн белəн кызыксынучы укучыларны ачыклау. | |
| 2 | Укучылар белəн эш дəфтəрлəре башлау. | |
| 3 | Укучыларның шəхси мөмкинлеклəрен ачыклау:<br>- үз фикерен ачык, төгəл əйтеп бирү сəлəте;<br>- эчтəлекне сөйли белү;<br>- терминнар куллана белү;<br>- грамоталылык;<br>- иҗадилык. | |
| 4 | Укучыларның логик фикерлəү сəлəтлəрен үстерү өстендə кызыклы материаллар белəн эшлəү | Газета –журнал материаллары, интернет ресурслар |
| 5 | Газета-журналларда татар теле һəм əдəбияты фəне темаларына караган ребуслар, кроссвордлар чишү, кызыклы материаллар өстендə эш. | Газета-журнал номерлары |
| 6 | Язучылар турында өстəмə мəгълүматлар туплау, папкалар эшлəү. | Газета –журнал материаллары, интернет ресурслар |
| 7 | Аерым темалар буенча тестлар эшлəү. | Татар теленнəн тестлар. |

| | | |
|---|---|---|
| 8 | “ Мәгариф” журналында чыгып килүче олимпиада биремнәрен чишү. | “ Мәгариф” журналы |
| 9 | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү | З.Н.Хәбибуллина. Сочинениене ничек язарга. |
| 10 | Картиналар буенча миниатюр – сочинениеләр язу. | Картиналар |
| 11 | Татар теле бүлекләре буенча тест биремнәре үтәү. | Татар теленнән тестлар. |
| 12 | Укучыларны мәктәп, район, республика олимпиадаларына әзерләү. | Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев. Хәзерге татар әдәби теле<br>М.З. Зәкиев. Татар грамматикасы.<br>Олимпиадага әзерләнү өчен ярдәмлекләр.<br>Максимов Н В. хезмәтләре.<br>Татар теленнән тестлар.<br>Узган уку еллары олимпиада сораулары. |
| 13 | Район, республика буенча сочинение конкурсларына әзерләү һәм катнаштыру | Д.С. Заһидуллина. Татар әдәбиятын укыту методикасы.<br>З.Н.Хәбибуллина. Сочинениене ничек язарга.<br>Үрнәк сочинениеләр, укучылар иҗаты |
| 14 | Сәләтле балаларның интеллектуаль үсешен тәэмин итәрдәй тестлар,махсус биремнәр эшләтү. | Һәр класс өчен йомгаклау тестлары.<br>Татар теленнән 222 тест. Х.Сәлим. |
| 15 | Республика газеталары белән бәйләнештә тору. | |
| 16 | Конкурсларда катнашу | Конкурс положениеләре |